КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 24 декабрь г.Казань № 1277

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждение-ләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 30 сентябрь, 931 нче карары белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарга үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 30 сентябрь, 931 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 25 ноябрь, 1124 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган 2022 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнарга, 4.1 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасының Энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесе».

2. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин